КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 март г.Казань № 216

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 декабрь, 622 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 декабрь, 622 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 10 декабрь, 706 нчы; 2007 ел, 29 декабрь, 800 нче; 2009 ел, 23 гыйнвар, 35 нче; 2009 ел, 11 декабрь, 849 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 31 гыйнвар, 56 нчы; 2011 ел, 5 март, 177 нче; 2011 ел, 18 ноябрь, 947 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 5 октябрь, 833 нче; 2013 ел, 19 ноябрь, 893 нче; 2014 ел, 21 апрель, 262 нче; 2014 ел, 9 сентябрь, 656 нчы; 2014 ел, 24 декабрь, 1018 нче; 2015 ел, 4 июнь, 409 нчы; 2015 ел, 7 август, 575 нче; 2016 ел, 3 июнь, 370 нче; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 26 сентябрь, 719 нчы; 2018 ел, 27 сентябрь, 869 нчы; 2018 ел, 10 декабрь, 1100 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1295 нче; 2020 ел, 27 май, 426 нчы; 2020 ел, 1 сентябрь, 770 нче; 2020 ел, 12 ноябрь, 1019 нчы; 2021 ел, 20 март, 153 нче; 2021 ел, 20 июль, 618 нче; 2021 ел, 10 август, 699 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турындагы нигезләмәгә, 4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Инспекциянең хокуклары

4.1. Инспекция түбәндәге хокукларга ия:

4.1.1. Бирелгән вәкаләтләр кысаларында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрергә.

4.1.2. Башкарылган эшләргә һәм кулланыла торган төзелеш материалларына үз көчләре белән, шулай ук, кирәк очракларда, махсуслаштырылган оешмаларны, фәнни-тикшеренү һәм проект институтларын, югары квалификацияле белгечләрне (экспертларны), галимнәрне Татарстан Республикасы бюджетында каралган акча һәм башка финанслау чыганаклары исәбеннән җәлеп итеп, экспертиза, тикшерүләр, лаборатория сынауларын һәм башка сынаулар үткәрергә.

Төзелешне гамәлгә ашыручы зат капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә башкарылган эшләргә һәм кулланыла торган төзелеш материалларына экспертизалар, тикшерүләр, лаборатория сынаулары һәм башка сынаулар үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү өчен акча түли. Әлеге акча төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге буенча өстәмә чараларны финанслау өчен бюджет керемнәре администраторының Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендәге шәхси счетына күчерелә.

4.1.3. Контроль (күзәтчелек) чаралары актларын төзергә, бирелгән вәкаләтләр кысаларында ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирергә.

4.1.4. Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә һәм (яки) административ хокук бозулар турындагы делоларны карап тикшерергә, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә һәм очракларда административ хокук бозулар турындагы делоларны үтәүне тәэмин итү чараларын кулланырга.

4.1.5. Гражданнарга, индивидуаль эшмәкәрләргә, юридик һәм вазыйфаи затларга карата алар тарафыннан шәһәр төзү эшчәнлеге өлкәсендә законнар бозылу турындагы материаларны катнашуны таләп итә торган контрольдә тоту, хокук саклау һәм суд органнарына җибәрергә.

4.1.6. Инспекция компетенциясенә караган функцияләрне башкару өчен кирәкле мәгълүматны башкарма хакимият органнарыннан, контрольдә тоту органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан законнар белән билгеләнгән тәртиптә алырга.

4.1.7. Контрольдә тотылучы затлардан законнар белән каралган тәртиптә аңлатмалар һәм документлар алырга.

4.1.8. Татарстан Республикасы законнары проектларын һәм башка норматив хокукый актларын эшләүдә катнашырга, Инспекция компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча әлеге норматив хокукый актларны камилләштерү турында тәкъдимнәр кертергә.

4.1.9. Күзәтчелек карамагындагы капиталь төзелеш объектлары реестрын һәм тиешле объектларның торышы турындагы мәгълүматларның белешмә бирү характерындагы базасын алып барырга.

4.1.10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Инспекция карамагындагы махсуслаштырылган лаборатория-сынау үзәкләрен төзү турында тәкъдимнәр кертергә.

4.1.11. Норматив һәм методик документлар проектларын эшләү, консультацияләр, экспертизалар үткәрү өчен, шулай ук контроль (күзәтчелек) чараларында катнашу өчен законнар белән билгеләнгән тәртиптә белгечләр җәлеп итәргә.

4.1.12. Үз компетенциясе чикләрендә норматив хокукый актлар чыгару, Инспекция компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча методик документлар, инструкцияләр эшләргә.

4.1.13. Судта үз компетенциясе чикләрендә билгеләнгән тәртиптә чыгыш ясарга.

4.1.14. Хокук саклау һәм суд органнары соратулары буенча үз компетенциясе чикләрендә билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат бирергә.

4.1.15. Инспекция компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча укыту чаралары, киңәшмәләр, семинарлар, конференцияләр оештырырга һәм үткәрергә.

4.1.16. Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән билгеләнгән тәртиптә идарә итүне гамәлгә ашырырга.

4.1.17. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру барышында җирле үзидарә органнары яки аларның вазыйфаи затлары тарафыннан башкарылган хокук бозуларны бетерү буенча язма күрсәтмәләр бирергә.

4.1.18. Тапшырылган дәүләт вәкаләтләре мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашырырга.

4.1.19. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле документларны, мәгълүматны һәм материалларны җирле үзидарә органнарыннан соратып алырга.

4.1.20. Билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә координацияләү һәм киңәшмә органнары, шул исәптән ведомствоара органнар (советлар, комиссияләр, төркемнәр, коллегияләр) төзергә.

4.1.21. Ведомство бүләкләрен гамәлгә куярга, алар белән бүләкләү турында карарлар кабул итәргә һәм Инспекциянең дәүләт граждан хезмәткәрләрен, эшчеләрен бүләкләүнең башка төрләрен кулланырга.

4.2. Инспекциянең вазыйфаи затлары законнар нигезендә үзләренә йөкләнгән бурычларны үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен җавап бирә.

4.3. Инспекциянең вазыйфаи затлары Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 9.4, 9.5, 9.5$^{1}$ статьяларында (капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан кылынган административ хокук бозулар өлешендә), 9.16 статьясындагы 3 өлешендә, 13.19$^{2}$ статьясындагы 1 өлешендә (күпфатирлы йортлар төзүне гамәлгә ашыручы торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан кылынган административ хокук бозулар өлешендә), 13.19$^{3}$статьясында (төзүче, төзүченең вазыйфаи затлары тарафыннан кылынган административ хокук бозулар өлешендә), 14.28 статьясындагы 1 – 5 өлешендә, 14.28$^{1}$, 14.44 статьяларында, 19.5 статьясындагы 4 өлешендә каралган административ хокук бозулар турындагы делоларны карап тикшерергә, шулай ук Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 6.3, 8.1 статьяларында, 17.7, 17.9 статьяларында, 19.4 статьясындагы 1 өлешендә, 19.4$^{1}$ статьясында, 19.5 статьясындагы 6 һәм 15 өлешләрендә, 19.6, 19.7 һәм 19.33 статьяларында, 20.4 статьясындагы 1, 2, 2$^{1}$, 6, 6$^{1}$ һәм 9 өлешләрендә,

20.25 статьясындагы 1 өлешендә каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә.

4.4. Инспекциянең вазыйфаи затлары Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының $20.6^1$ статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә хокуклы.»;

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карарның 1 пунктындагы өченче абзацының гамәле 2022 елның 31 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла;

бу карарның 1 пунктындагы егерме сигезенче абзацы 2021 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне кертеп) гамәлдә була.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин